**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

17.08.2026 925-п

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгында вазыйфаи бурычларын үтәү дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга бәйле булган, билгеләгәндә конкурс үткәрелмәскә мөмкин булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 14.08.2017 ел, № 952-п боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

«Рәсәй Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясындагы 3 өлеше нигезендә, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгында вазыйфаи бурычларын үтәү дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга бәйле булган, билгеләгәндә конкурс үткәрелмәскә мөмкин булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 14.08.2017 ел, № 952-п боерыгына (16.09.2020 № 1008-п, 20.12.2021 № 1442-п боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

преамбулада «Рәсәй Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 6 февралендәге 63 номерлы карары белән расланган Рәсәй Федерациясе вазыйфаи затларын һәм гражданнарын дәүләт серенә кертү тәртибе турында инструкция белән» сүзләрен «Рәсәй Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 7 февралендәге 132 номерлы «Рәсәй Федерациясе вазыйфаи затларын һәм гражданнарын дәүләт серенә кертү кагыйдәләрен раслау турында» карары белән» сүзләренә алмаштырырга;

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгында вазыйфаи бурычларын үтәве дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрдән

файдалануга бәйле булган, билгеләнгән боерык белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге яңа редакциядә бәян ителергә тиеш (кушымта итеп бирелә).

2. Хокукый тәэмин итү бүлегенә әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Министр А.И. Җиһаншин

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының 14.08.2017 № 952-п боерыгы белән расланган
(«17» август 2026 ел. № 925-п боерыгы редакциясендә)

Исемлек
Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгында вазыйфаи бурычларын үтәү дәүләт серен тәшкил итә торган мәгълүматлардан файдалануга бәйле булган, билгеләгәндә конкурс үткәрелмәскә мөмкин булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары

1. Эшләр белән идарә итүче.
2. Министр ярдәмчесе
3. Финанс контроле, исәп-хисап һәм хисап бүлеге башлыгы.
4. Финанс контроле, исәп-хисап һәм хисап бүлегенең әйдәп баручы белгече.
5. Дәүләт кадрлар хезмәте бүлеге башлыгы.
6. Дәүләт кадрлар хезмәте бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе.
7. Хокукый тәэмин итү бүлеге башлыгы.
8. Икътисад һәм проект эшчәнлеге идарәсе башлыгы.
9. Мәгълүмат системалары һәм экологик агарту идарәсе башлыгы.
10. Мәгълүмат системалары һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү бүлеге башлыгы.
11. Мәгълүмат системалары һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү бүлегенең әйдәүче киңәшчесе.
12. Мәгълүмат системалары һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү бүлегенең әйдәп баручы белгече.
13. Экологик куркынычсызлыкны һәм экологик мониторингны тәэмин итү идарәсе башлыгы.
14. Планлаштырылган эшчәнлекне бәяләү бүлеге башлыгы.
15. Экологик нормалаштыру бүлеге башлыгы.
16. Экологик мониторинг бүлеге башлыгы.
17. Әйләнә-тирә мохитне саклау идарәсе башлыгы.
18. Атмосфера һавасын саклау бүлеге башлыгы.
19. Су объектларын саклау бүлеге башлыгы.
20. Җир ресурсларын саклау бүлеге башлыгы.
21. Җитештерү һәм куллану калдыклары белән имин эш итүне тәэмин итү бүлеге башлыгы.
22. Минераль-чимал һәм су ресурслары идарәсе башлыгы.
23. Углеводород чималы геологиясе бүлеге башлыгы.

24. Каты файдалы казылмалар геологиясе бүлеге башлыгы.
25. Гидрогеология һәм судан файдалануны җайга салу бүлеге башлыгы.
26. Җир асты байлыкларыннан файдалану мөнәсәбәтләрен җайга салу идарәсе башлыгы.
27. Җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү бүлеге башлыгы.
28. Мәгълүмати геологик ресурслар һәм геологик мохит мониторингы бүлеге башлыгы.
29. Җир асты байлыкларыннан файдалануны җайга салу бүлеге башлыгы.
30. Экологик күзәтчелек дәүләт инспекциясе идарәсе башлыгы.
31. Күзәтчелек эшчәнлеге мониторингы бүлеге башлыгы.
32. Геологик күзәтчелек бүлеге башлыгы.
33. Экологик күзәтчелек бүлеге башлыгы.
34. Административ-хуҗалык бүлеге башлыгы.
35. Мобилизацион эш, гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр секторы мөдире.
36. Мобилизацион эш, гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча әйдәп баручы белгеч.
37. Үзәк территориаль идарә башлыгы.
38. Үзәк территориаль идарә башлыгы урынбасары.
39. Кама буе территориаль идарәсе башлыгы.
40. Төньяк территориаль идарәсе башлыгы.
41. Идел аръягы территориаль идарәсе башлыгы.
42. Идел-Кама территориаль идарәсе башлыгы.
43. Кама аръягы территориаль идарәсе башлыгы.
44. Көньяк-Көнчыгыш территориаль идарәсе башлыгы.
45. Ык буе территориаль идарәсе башлыгы.